## Котлыйбыз!

**Вагыйз кызы Сания Мингачеваның туган көне!**

Сәламәтлек, озын гомер язсын,
Гел көләч һәм яшь бул хәзергечә.
Күңелең синең күтәренке булсын,
Сөенеп һәм сөендереп мең-мең яшә.

*Якыннарың.*

***

**Габделкаюм кызы Минҗиан Хәйрулловага - 70 яшь!**

Сабыр холыклы, мәрхәмәтле, кадерледән кадерле син. Киләчәктә дә киң күңелле, ачык йөзле, олы йөрәкле булып кал. Ходай сиңа алдагы көннәреңдә дә сәламәтлек белән гомер итәргә насыйп итсен иде.
Син бит, кадерлебез, безнең өчен кояш,
Синнән нурлар алып яшибез.
Озак яшә, газизебез, мәңге яшь бул,
Иң кадерле якын кешебез.

*Ирең Әнвәр, улың Айрат.*

***

**Габделкаюм кызы Минҗиан Хәйрулловага!**

Туар таңнарың тыныч, саулыгың ныклы, гомерең бәхетле булсын. Авырмый, кайгы-хәсрәт күрми, озын гомер итүеңне, якыннарыңның игелеген күреп яшәвеңне язсын Аллаһы Тәгалә.
Кояшлы көн телибез сиңа, дустым,
Болытларны куып таратып.
Яшик әле алда гомер барда,
Якын дуслар булып яратып.

*Дусларың Касыйм, Мәдхия балалары һәм оныклары белән.*

***

**Әбугали кызы Гөлчәчәк Нуруллинаның туган көне!**

Озын булсын сезнең гомерегез,
Тыныч булсын һәрчак күңелегез.
Бәхет чишмәләрегез мул аксын,
Зур шатлыклар белән таң атсын.

*"Сәлам" гәҗитәсе хезмәткәрләре.*

***

**Минхалим кызы Мария Шакированың туган көне!**

Тормыш юлыгыз һәрчак балкып торсын,
Ягымлы, шат булсын күңелегез.
Озын гомер, бәхет-шатлык белән
Бер кайгысыз үтсен гомерегез.

*"Сәлам" гәҗитәсе хезмәткәрләре.*

***

**Әсфир кызы Айгөл Хәкимованың туган көне!**

Котлы булсын бәйрәмегез,
Тыныч булсын күңелегез.
Шатлык-сөенечләр белән
Тулы булсын гомерегез.

*"Сәлам" гәҗитәсе хезмәткәрләре.*

***

**Ришат кызы Лилия Әпсәләмованың туган көне!**

Зур бәхетләр юлдаш булсын сезгә,
Көннәрегезне шатлык бизәсен.
Сәламәтлек - иң зур бәхет бит ул,
Шушы бәхет читләп үтмәсен.

*"Сәлам" гәҗитәсе хезмәткәрләре.*


***

**Ринат кызы Юлия Йосыпованың туган көне!**

Озын гомер бирсен Хак Тәгалә,
Тыныч булсын һәрчак җаннарыгыз,
Кочак-кочак бетмәс куанычлар
Төяп килсен туар таңнарыгыз.

*"Сәлам" гәҗитәсе хезмәткәрләре.*

**Бездә котлаулар һәм игъланнар бушлай.**
Миләүшәгә мөрәҗәгать итегез
**8-937=207-08-88**
**932-58-67**
Каб. №26
e-mail: milana3105@yandex.ru



## Дини сүзлек

**Тәҗвид** - Коръәнне уку кагыйдәләре.

**Гыйддәт вакыты** - хатынның ире үлгәннән соң йәки иреннән аерылгач, яңадан никахлашмыйча көтеп торуы.

**Хәйриләт** - бүләк, сәдака бирү.

**Мөҗтәһид** - үзенең гыйлеме һәм карашы белән Коръәннән һәм хәдис-шәрифтән хөкем чыгаручы.

**Тәваф** - әйләнеп йөрү.

**Мөкамәл** - камил (совершенный).

**Гафләт** - игътибарсызлык.

**Вәгазь** - яхшы сүз.

**Мәкруһ** - шелтәгә лаеклы.

**Хәрам** - тыелган.

**Вәҗип** - мәҗбүр.

**Дөрбә** - мавзолей.

**Нәфел** - өстәмә.

**Фасыйк** - бозык.

**Мизан** - үлчәү.

**Дәгъват** - Исламга өндәү.

**Гареб** - Көнбатыш.

**Мөвәххидләр** - бер Аллаһыга ышанучылар.

**Татар халык мәкальләре**

## Ачуын йота алган кеше чын батыр булыр

**Бирим** дигән колына чыгарып куяр юлына.

**Сиңа** язган ризык телеңне сындырып керә.

**Һәр** авырлыктан соң җиңеллек килә.

**Сызлаган** тәнгә җан әрнүе өстәмәгез.

**Җаны** теләгән җылан ите ашаган.

**Дуслар** күп булмый.

**Ният** иткән теләгенә ирешкән.

**Тирән** күл серле була.

**Балык** тирән су эзли.

**Шәхси** үрнәк - иң яхшы тәрбия.

**Җан** тартмаса - кан тарта.

**Яхшылык** эшлә дә суга сал.

**Йөрәк** янмаса, күздән яшь чыкмый.

**Читтән** караган яхшырак күрә.

**Каләм** белән язганны балта белән чабып ташлап булмый.

**Сөйләүче** күп лә ул, эшләп күрсәтергә кирәк.

**Коллары** - корыч, телләре - борыч.

**Эзләсәң** - табыла, күрә белсәң - күренә ул.

**Ачуын** йота алган кеше чын батыр булыр.

Мәгълүматларны **Шамил БАҺАУТДИН** туплады.

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.): "Шигырьдә хикмәт бар"**

## Рәсәй илен данга күмгән татарларым!

Татарларым!
Минем татарларым!
Дан яулаган хезмәт батырларым.
Динне яклап, телне саклап,
безнең өчен
Гомерен биргән ата-бабаларым.

Җир шарына сибелгәннәр
татарларым,
Югалмаган тик аларда татар җаны.
Милләтем, дип, янып яши татарларым,
Дине өчен кайнап тора аның каны.

Татарларым!
Сездә нәсел тамырларым,
Михнәт белән кайгы катыш
шатлыкларым.
Гореф-гадәт җебен эрләп-үреп,
Яшь буынга тәрбия биргән
тарихларым.

Татарларым!
Лачын татарларым,
Киң күңелле, уңган әби-бабаларым.
Ак яулыклы сабыр апаларым -
Бар да алар милләт йолдызларым.

Халкымның әтәр көче - абыйларым,
Милләтемнең йөзек кашы - йәш
кызларым.
Сездә бөтен киләчәге милләтемнең,
Батыр, көчле, моңлы калсагызчы,
туганнарым.

"Мин - татар!" дип, горур әйтеп була
бүген,
Хөрмәт итә безне һәрбер милләт,
кавем,
Кем ышаныр иде элек бу хәлләргә?
"Икенче сорт син", дип йөргән
дәверләрдә.

Таптадылар тырышып татарымны,
Сөргеннәргә сөрелсә дә, җуелмады.
«Чукын!» диеп камчылаган чакта да ул
Бирешмәде, үз кыйбласына
сәҗдә кылды.

Мәсҗидләрем тулы хәзер
халык белән,
Мин халкымның үсеш юлын
диндә күрәм.
Үз малларын алар сарыф итә
изге эшкә,
Ифтар җыя, хаҗга бара, корбан чала.

Татарларым!
Минем татарларым!
Өмет баглап аткан ал таңнарым.
Рәсәй илен данлыкларга күмә
Җиңелү белмәс
мәшһүр татарларым!

**Наилә ХӨСӘЕНОВА.**
Иске Мастяк - Самар.

## Тәмугка керү җиңелме, әллә...

"Әйтегезче, тәмугка керү җиңелме,
әллә җәннәткәме?»
Әлбәттә, җәннәткә!
Җәннәт юлы - бушлай,
тәмугныкы - түләүле.
Тәмәке тартасың - акча түлисең,
аракы эчәсең - акча түлисең,
зина кыласың - акча түлисең.
Мәсҗидкә рәхим ит.
Намаз кылу бушлай.
Ураза тоту бушлай.
Шулай булгач, уйланыйк, җәмәгать!

Татарстан мөфтие **Камил** хәзрәт **СӘМИГУЛЛИН.**

## Котлыйбыз!

**Чәчәкләр патшабикәсе Дания Хәйруллинаның юбилее!**

Кеше үз гомерендә ике мәртәбә яшьлек хисләрен кичерә.
Беренчесе - утыз биш яшькә кадәр тоташ яшьлек.
Икенчесе - картлыкның яшьлеге алтмышта.
Дания ханым менә шул чикне бик матур каршы ала.
Ул һәрвакыт хәрәкәттә.
Аның кебекләр турында халкым:
«Очып йөри», - ди.
Кызлардай зифа.
Елмаеп кына сөйләшә.
Чәчәкләр патшабикәсе!
Ул ничә төрле чәчәк үстергәнен үзе дә белми.
Бакчасы кызыл, зәңгәр, сары, алсу, шәмәхә төсләрдән чигелгән зур келәмне хәтерләтә.
Шул ук вакытта түтәлләрдә дистәләгән яшелчә өлгереп утыра!
Иң мөһиме - барлык яшелчәнең үсентеләрен үзе үстерә.
Каргалар чукымасын дип, һәр карбыз-каунны чүпрәк белән чорнап куяр.
Гөмбәләрне җыю, тозлау, маринадлау буенча маржаларны уздыра.
Камыр ашлары пешерү буенча - татар хатынының бизмәне.
Иргә тәрбия күрсәтү буенча аңа тиңнәр сирәктер.
Туганлык хисләрен саклау буенча - ул күчергеч.
Кыямәт көнне адәмгә биреләчәк сораулар арасында:
«Яхшы эшләр эшләүче бар идеме?» дигән сорау да булачак ди Китап.
Дания ханым - яхшы эшләр эшләүчеләр исемлегендә.
Сезләргә ике дөньяның нигъмәтләрен бирсә иде
Аллаһы Тәбарәкә үә Тәгалә!

*«Сәлам» гәҗитәсенең җаваплы сәркатибе һәм хатлар бүлеге мөдире Шамил Баһаутдин.*

***

**Минхәер кызы Әлфия Суфьянованың туган көне!**

Көчле рухлы һәм кешелекле, юмарт һәм ярдәмчел син. Туар таңнарың тыныч, саулыгың ныклы, гомерең бәхетле булсын. Кайгы-хәсрәт күрми, озын гомер итүеңне, якыннарыңның игелеген күреп яшәргә язсын Ходай.
Син булганда гына без бәхетле,
Син булганда якты көнебез.
Кыш аенда ишелеп кар яугандай,
Ап-ак бәхет-шатлык телибез.

*Сөнгатуллиннар һәм Нуршакировлар гаиләләре.*

***

**Минхәер кызы Әлфия Суфьяновага!**

Сабыр холыклы, йомшак, мәрхәмәтле, ярдәмчел сез. Киләчәктә дә киң күңелле, ачык йөзле, олы йөрәкле булып калыгыз. Сезгә сәламәтлек, бәхет-шатлыклар, җан тынычлыгы, мул тормыш телибез.
Карашларыгыз җылы яңгыр кебек,
Елмаюыгыз айдай сөйкемле.
Шәфкатегезнең иге-чиге юк бит,
Кояш чәчкән нурлар шикелле.

*"Сәлам" гәҗитәсе хезмәткәрләре.*

***

**Исламнур кызы Нурия Мостафинага - 55 яшь!**

Ныклы сәламәтлек, җан тынычлыгы, гаилә шатлыгы, хәерле озын гомер телибез. Якыннарыңның, туганнарыңның, балаларың-оныкларыңның кадерен тоеп яшәргә язсын сиңа Ходай.
Күпме булса җирдә изге теләк,
Без телибез сиңа барын да.
Гомер юлың, якты кояш кебек,
Бәхетле бул син һәрбер көнеңдә.

*Әниең Ләбибә, ирең Җәйһүн, абыйларың Исмәгыйль, Хәмит Яриәхмәтовлар гаиләләре белән, балаларың Илфат, Илнур, Катя, Алеша, Захар, киленең Юлия, оныкларың Карина, Альмира һәм Дамир, Фәния Сәлахова, туганнарың, дусларың.*